**РАСЛЫЙМ**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, Мөфти
Камил хәзрәт Сәмигуллин

________________________

«20» ___09___ 2016 ел

**РАСЛЫЙМ**
«Россия ислам институты» ректоры
Р.М. Мөхәммәтшин

________________________

«20» ___09___ 2016 ел

## «Таян Аллага» әдәби конкурсының
## НИГЕЗЛӘМӘСЕ

**I. Конкурсның гомуми нигезләмәләре**

**1.1**. “Таян Аллага” әдәби конкурсы Россия Федерациясендә яшәүче татар яшьләре арасында яшь талантларны барлау һәм берләштерү, аларның иҗади эшчәнлекләрен үстерү максатында уздырыла.

Конкурсның бурычлары:

- сәләтле яшьләргә иҗади үсеш өчен шартлар булдыру;
- татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен һәм ислам динен пропагандалау.

Оештыручылар:

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте, Россия ислам институты.

**1.2.** Вакыты һәм үткәрү тәртибе

Конкурс өч этапта үтә:

1 этап — әсәрләрне җыю (1 октябрь 2016 ел – 31 гыйнвар 2017 ел)

2 этап — әсәрләрне жюри тарафыннан бәяләү (1 февраль – 31 март 2017 ел).

3 этап — җиңүчеләрне бүләкләү (май 2017 ел).

**II. Конкурста катнашу шартлары**

**2.1.** Конкурста Россия Федерациясендә яшәүче 10 яшьтән 35 яшькә кадәрле һәрбер теләгән кеше катнаша ала.

**2.2.** Конкурс иҗат эше белән профессиональ рәвештә шөгыльләнмәүче яшьләр өчен үткәрелә, профессиональ язучыларның, шагыйрьләрнең, журналистларның әсәрләре һәм язмалары кабул ителми.

**2.3.** Конкурс дүрт номинациядә үтә:

- шигърият,
- чәчмә әсәрләр,
- драматургия,
- публицистик язмалар.

**2.4.** Конкурска тәкъдим ителгән әсәрләр һәм мәкаләләр **татар телендә** язылырга тиеш.

**2.5.** Аз күләмле әсәрләрне (шигырьләр, кыска хикәяләр һ.б.) һәм публицистик язмаларны өчтән дә ким җибәрмәү сорала. Аларны түбәндәге таләпләргә туры китереп эшләргә кирәк: Times New Roman шрифтында, 14 нче кегль, бер ярым интервалда, сул яктан – 30 мм, уң яктан – 10 мм, өстән – 25 мм, астан – 20 мм.

**2.6.** Конкурска язмалар электрон вариантта кабул ителә. Конкурс материалларын җибәрү өчен электрон адрес: tatarkonkurs@mail.ru

**2.7.** Әсәрләр белән бергә конкурста катнашучы үзе турында кыскача мәгълүмат, адресын һәм телефон номерын җибәрергә тиеш. Конкурска җибәрелгән материалларны алу белән, оештыру комитеты авторларның электрон почтасына раслау җибәрә. Мондый хәбәр килмәгән очракта, конкурста катнашучыга язмасын тагын бер кат җибәрергә яисә http://www.kazanriu.ru, http://dumrt.ru сайтларыннан, яңалыклар бүлегендә исемлектән карап белергә мөмкин булачак (исемлек атна саен яңартылачак). Конкурс белән бәйле барлык мәгълүматлар да сайтка урнаштырылачак.

## III. Конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

3.1. Конкурста катнашучыларның әсәрләрен анализлау һәм бәяләү өчен оештыру комитеты тарафыннан махсус комиссия (жюри) билгеләнә.

3.2. Комиссия, конкурска килгән язмаларны тикшереп, һәр номинациядә беренче, икенче, өченче урыннарны һәм гран-прига лаек әсәрне билгели. Моннан тыш, махсус бүләкләр булуы да мөмкин.

Жюри гран-при һәм призлы урыннарны бирмәү хокукына да ия.

Конкурс нәтиҗәләре буенча «Таян Аллага» исемле җыентык чыгарыла. Ул конкурска килгән иң яхшы әсәрләрдән туплана.

Оештыру комитеты адресы: Казан ш., Газовая урамы, 19 нчы йорт. Татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы. E-mail: tatarkonkurs@mail.ru

Белешмәләр өчен телефон: 8(843)2776826